**Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7278**
**25.12.2020**

Башкарма комитетның 2019 елның 31 октябрендәге 5597 номерлы карары белән расланган 2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2019 елның 31 октябрендәге 5597 номерлы карары (Башкарма комитетның 2020 елның 6 апрелендәге 1695 номерлы, 2020 елның 12 октябрендәге 5229 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган 2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 бүлекнең 6 пунктында «Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау, мең сум» баганасындагы «2020 (мең сум)» графасында «158,0» цифрын «138,0» цифрына алмаштырырга;

2) 6 бүлекнең 11 пунктында «Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау, мең сум» баганасындагы «2020 (мең сум)» графасында «20,0» цифрын «40,0» цифрына алмаштырырга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов